ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2022 елның 25 гыйнвары** **Чистай шәһәре** **№ 32**

Чистай муниципаль районы буенча
2022 елның I кварталына торакның
1 квадрат метр гомуми мәйданының
уртача базар бәясе турында

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «2022 елның беренче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе һәм торак урынның гомуми мәйданының Россия Федерациясе субъектлары буенча 2022 елның I кварталына бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2021 елның 17 декабрендәге 955/пр номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2022 елның I кварталына Чистай муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар бәясен (сумнарда), күрсәтелгән социаль түләүләр федераль бюджет акчалары исәбеннән бирелә торган барлык категориядәге гражданнар өчен социаль түләүләр күләмнәрен исәпләп чыгару өчен, 96 108 (туксан алты мең йөз сигез) сум күләмендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары П.Б. Емельяновка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р.Хәсәнов